ГЛАВА ПИЖМАРСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
БАЛТАСИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
ПЫЖМАРА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**25.12.2025 ел** **№9**

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының «Пыжмара авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге чикләрен туры китерү мәсьәләсе буенча гавами тыңлаулар үткәрү турында**

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы муниципаль берәмлекләре чикләре турында» Татарстан Республикасы Балтач район Советының 2025 елның 17 декабрендәге 28 номерлы карары, «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Пыжмара авыл җирлегендә гавами тыңлаулар (җәмәгать фикер алышулары) үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Пыжмара авыл җирлеге Советының 2020 елның 29 маендагы 133 карары нигезендә Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының «Пыжмара авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге чикләрен гавами тыңлаулар уздыру юлы белән туры китерү турындагы мәсьәләне тикшерүдә гражданнарның катнашу хокукларын үтәү максатларында карар кабул итәм:

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының «Пыжмара авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге чикләрен Татарстан Республикасы чигенә туры китерү мәсьәләсе буенча Киров өлкәсе белән чиктәш җирдә 2026 елның 14 гыйнварына 11.00 сәгатькә Пыжмара авыл җирлеге бинасында түбәндәге адрес буенча гавами тыңлаулар билгеләргә: ТР, Балтач муниципаль районы, Пыжмара авылы, с. Мулеков урамы, 19 йорт.

2. Гавами тыңлауларда карала торган мәсьәләләр буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр 2026 елның 13 гыйнварына кадәр түбәндәге адрес буенча кабул ителә: ТР, Балтач муниципаль районы, Пыжмара авылы, С.Мулеков урамы, 19 йорт (Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Пыжмара авыл җирлеге башкарма комитетының административ бинасы). Консультацияләр өчен Телефон: 8 (843)68-3-67-38.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматын рәсми порталында бастырып чыгару юлы белән халыкка җиткерергә (https://pravo.tatarstan.ru), «Хезмәт» матбугат-редакция газетасында, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (https://baltasi.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Пыжмара авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында:

- Пыжмара ав., С. Мулеков ур., 21 йорт,
- Сәрдек ав., Тынычлык ур., 22 йорт,
- Иске Пукшинера ав., Дуслык ур., 2 һәм 4 йортлар арасында,
- Әтнә ав., Комсомол ур., 21 йорт.,
- Сардек ав., Заря ур., 13нче йорт.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Пижмар авыл җирлеге башлыгы
Балтач муниципаль районы
Татарстан Республикасы Р.Х.Заляев